# *Синсез язлар миңа кирәк түгел*

*Кояш Тимбикова* сүзләре






1985

Язларны мин көтеп ала идем:
Якты нурлар, гөлләр чоры яз.
Ялгыз калган моңсу минем җанга
Язгы җилләр назы гына аз. } 2 тапкыр

Язлар язга охшамыйлар икән,
Быелгы яз безне аерды.
Сайрар кошларым да моңайган күк,
Хыял канатларым кайрылды. } 2 тапкыр

Язларыңда ялгыз калма икән,
Шифасы тик сагыш арттыра.
Гөлләрем дә сине юксыналар,
Яннарыма тизрәк кайт кына! } 2 тапкыр

Синсез язлар кирәк түгел миңа,
Җырым тулы сагыш, моң гына.
Син кайтачак бәхет көзен көтәм,
Сабыр гына көтәм, тын гына. } 2 тапкыр